РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Сосновского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423596, Нижнекамский район,
д. Благодатная, ул.Мира, 64

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Сосновка авыл җирлеге
Башкарма комитеты

423596, Түбән Кама районы,
Благодатная авылы, Тынычлык урамы, 64

тел./факс (8555) 33-14-17, электронный адрес: Sosnovskoe.sp@tatar.ru, сайт: www.sosnovskoe-sp.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

05.07.2022ел № 4

**Сосновка авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 27 мартында кабул ителгән 4 номерлы карары белән расланган Сосновка авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләүне үткәрү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы карары нигезендә, Сосновка авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Сосновка авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 27 мартында кабул ителгән 4 номерлы карары белән расланган Сосновка авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләүне үткәрү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 пунктта «, муниципаль программаларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

12 пунктта:

икенче абзацта «, муниципаль программаларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 еллык чорда ташламалардан файдаланган түләүчеләр саны һәм ташламалардан файдалану өчен потенциаль хокукка ия түләүчеләр саны яки түләүчеләрнең гомуми саны белән нисбәттә характерлана торган күрсәтелгән ташламаларга түләүчеләрнең ихтыяҗы.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

А.Н. Бурчин